ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктының һәм 83 статьясындагы 9 өлешенең конституциячел булуын тикшерү хакында гарызнамә белән Россия Федерациясе Конституция Судына мөрәҗәгать турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Конституциясенең 125 статьясы, «Россия Федерациясе Конституция Суды турында» 1994 елның 21 июлендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «а» пунктчасы, 36, 37, 84 статьялары нигезендә «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктының һәм 83 статьясындагы 9 өлешенең конституциячел булуын тикшерү хакында гарызнамә белән Россия Федерациясе Конституция Судына мөрәҗәгать итәргә.

2. «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктының һәм 83 статьясындагы 9 өлешенең конституциячел булуын тикшерү турындагы гарызнамәне Россия Федерациясе Конституция Судында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы юстиция министры, юридик фәннәр кандидаты Заһидуллин Рөстәм Илдус улын билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2307-VI ДС